КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 16 ноябрь г.Казань № 998

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2 бүлектә:

2.4 нче пунктның таблицасында:

| | | |
|---|---|---|
| «Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Фельдшер | 11 700» |
| | Процедуралар шәфкать туташы | |
| | Бәйләү буенча шәфкать туташы | |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Акушер | 11 700»; |
| | Фельдшер | |
| | Процедуралар шәфкать туташы | |

| | | |
|---|---|---|
| | Бәйләү буенча шәфкать туташы | |

2.6 нчы пунктның таблицасында:

| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
|---|---|---|---|
| «Культоештыручы | 9 489 | 10 000 | 10 300» |
| Аккомпаниатор | | | |

бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
|---|---|---|---|
| «Культоештыручы<br>Аккомпаниатор | 9 489 | 10 000 | 10 300»; |

түбәндәге эчтәлекле 2.7 нче пункт өстәргә:

«2.7. Хезмәткәр Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәсе яки һөнәри стандартлар белән билгеләнгән дәрәҗәдән түбәнрәк булган белем дәрәҗәсендәге вазыйфага кабул ителгән очракта, аңа таләп ителә торган белем дәрәҗәсе нигезендә база оклады билгеләнә.

Хезмәткәрнең белем дәрәҗәсе Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәсе яки һөнәри стандартлар белән билгеләнгән дәрәҗәдән югарырак булганда, аңа таләп ителә торган белем дәрәҗәсе нигезендә база оклады билгеләнә.»;

6 бүлектә:

6.8.9 нчы пунктта:

22 таблицаның 2 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| 2. | «Урта медицина фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | |
|---|---|---|
| 2.1. | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 35 |
| 2.2. | Хезмәт терапиясе буенча инструктор | 35 |
| 2.3. | Стерилизацияләү бүлеге шәфкать туташы | 35 |
| 2.4. | Медицина дезинфекторы | 35 |
| 2.5. | Балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы буенча табиб (туклану гигиенасы буенча табиб, хезмәт гигиенасы буенча табиб, гигиена тәрбиясе бирү буенча табиб, коммуналь гигиена буенча табиб, гомуми гигиена буенча табиб, табиб-паразитолог, радиация гигиенасы буенча табиб, табиб-эпидемиолог) ярдәмчесе | 37 |
| 2.6. | Медицина теркәүчесе | 35 |
| 2.7. | Диета буенча шәфкать туташы | 37 |
| 2.8. | Шәфкать туташы | 40 |
| 2.9. | Палата (пост) шәфкать туташы | 40 |
| 2.10. | Физиотерапия буенча шәфкать туташы | 40 |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. | Массаж буенча шәфкать туташы | 40 |
| 2.12. | Акушер | 45 |
| 2.13. | Фельдшер | 45 |
| 2.14. | Процедуралар шәфкать туташы | 45 |
| 2.15. | Бәйләү буенча шәфкать туташы | 45 |
| 2.16. | Өлкән шәфкать туташы (акушер, фельдшер, операция шәфкать туташы, теш техникы) | 50»; |

6.9 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Авыл җирлегендә эшләгән өчен түләүләр авыл җирендә социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы, «Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә икенче дәрәҗәдәге һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы белгечләр вазыйфалары» һәм «Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә өченче дәрәҗәдәге һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә бирелә.».

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 699 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 сентябрь, 837 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта:

бишенче абзацта «бишенче» сүзен «алтынчы» сүзенә алыштырырга;

алтынчы абзацта «алтынчы» сүзен «җиденче» сүзенә алыштырырга.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның 1 нче пунктындагы беренче – унөченче абзацларның гамәле 2018 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

бу карарның 2 нче пунктындагы өченче – дүртенче абзацларның гамәле 2018 елның 22 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин